РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
АЛЬШИХОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛШИХ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

30 декабрь 2022 ел № 59-2

Физик затлар мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә ярашлы рәвештә, Алших авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Алших авылы җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салымны мәҗбүри түләүгә кертергә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге зурлыкта билгеләргә:

1) 0,1 процент нисбәтендә:

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннарына;

мәйданнары 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмаларына карата;

2) 0,1 процент нисбәтендә:

фатир;

бүлмә;

3) 0,1 процент нисбәтендә:

торак йортлар;

тәмамланмаган төзелеш объектлары, мондый объектларның проектлаштырыла торган билгеләнеше торак йорт булса;

составына ким дигәндә бер торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

4) 2 процент нисбәтендә:

Россия Федерациясе Салым кодексының 378_2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;

Россия Федерациясе Салым кодексының 378_2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары, шулай ук кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;

5) 0,5 процента в отношении прочих объектов налогообложения.

3. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

- 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар;

- әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән гражданнар балаларын;

- «Россия Федерациясендә (алга таба - хәрби хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзаларын өлешчә мобилизацияләү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Хәрби Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) хәрби хезмәткәрләр белән никахта торучы ир яисә хатын;

2) 18 яшькә җитмәгән яки аннан өлкәнрәк булган, әгәр алар 18 яшькә җиткәнче инвалид булсалар, шулай ук белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы

буенча укучы, уку тәмамланганчы, әмма алар 23 яшькә җиткәнче хәрби хезмәткәр балалары;

3) хәрби хезмәткәрнең әти-әнисе.

4. Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, фатир өлеше яки бүлмә;

2) торак йорт яки торак йортның бер өлеше.

Салым ташламасы гаиләгә туры килә торган бер салым салу объектына карата салым түләүченең сайлавы буенча бирелә. Салым ташламасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан салым түләүче милкендә булган һәм салым түләүче тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы күләмендә бирелә.

Түләнергә тиешле салым түләүче тарафыннан салым ташламасы суммасын билгеләгәндә салым түләүчене сайлау буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата салым ташламалары куллану өчен нигезләрнең санына карамастан бирелә.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым ташламасына салым чоры булып торучы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча салым ташламасына хокукны раслаучы документлар бирергә хокуклы. Сайланган салым салу объектлары турындагы хәбәр салым органына дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин.

5. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Алших авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 1-48 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарын (25.05.2015 № 1-59, 08.10.2015 № 2-1, 20.06.2018 № 50-1, 29.09.2018 № 57-1, 19.08.2020 № 88-2 редакциясендәгн карарлары) көчен югалткан дип танырга.

6. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2022 елның 15 сентябрендәге 52-2 номерлы Алших авыл җирлеге Советының карарын гамәлдән чыгарырга.

7. Әлеге карар 2021-2022 еллардагы салым чорында физик затлар мөлкәтенә салымны исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

8. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http//buinsk.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Совет рәисе, Буа муниципаль районының
Алших авыл җирлеге башлыгы А.П. Андреев